СӨЙ ГОМЕРЕҢЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

21 ноябрь, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.

№ 131 (8143)

Бәясе билгеләнгәнчә

# Район тормышы: яңалыклар, хәбәрләр

*Татлы тамырны - дәүләткә*


## КҮРШЕ КҮРШЕДӘН КАЛЫШМЫЙ

**Ике күрше - «1нче Май» һәм Синдряков исемендәге хуҗалыклар дәүләткә шикәр чөгендере сату буенча килешү йөкләмәләрен үтәүдә дә бер - берсеннән калышмадылар. Йөкләмәләре дә бер чама иде аларның - 2860 һәм 2700 тонна. Сишәмбе көнне «1нче Май»дан килгән 14 йөк татлы тамырның бер өлеше инде йөкләмәдән тыш исәпкә языла башласа, күршеләре изге бурычларын икенче көнне тутырдылар. Хуҗалыкларның беренчесе әле йөкләмәдән тыш тагын шактый шикәр чималы озатырга ниятли.**

**Шулай итеп, татлы тамыр тапшыру буенча килешү йөкләмәсен уңышлы башкарып чыккан хуҗалыклар саны сигез булды. Шул исәптән заводның ярдәмче хуҗалыгы йөк-ләмәне 186, «Төр-нәс» 154, «Кондырча» һәм «Рассвет» 124әр, «Агрохимсервис» ярдәмче хуҗалыгы 115 процентка үтәде. Иң күп чөгендер Хафизов исемендәге хуҗалыктан керде - йөкләмәдәге 10200 урынына кичәге көнгә тапшырылганы 10819 тонна булды. «Родина»да да килешү йөкләмәсен тутыру өчен аз гына тырышасы калды. Соңгы бер көндә биредән заводка 34 йөк чөгендер китерелде. Ә ул көнне машинаның иң күбе - 53е - «Киекле»дән иде.**

Николай мәктәп яшеннән үк комбайнчы ярдәмчесе булып йөрсә дә, үзенә комбайн алып мөстәкыйль рәвештә эшләгәне юк иде әле. Әллә җөрьят итмәде, әллә башка нәрсә сәбәп булды. Ә анардан ярдәмче - бер дигән. Техниканы әйбәт белә, кирәккәндә штурвал артына да утыра. Тырышлыгы, үҗәтлеге дә зур. Хәер, бу сыйфатлар Камышлыдагы аларның Николаевлар династиясендәге барлык механизаторларга да бер дәрәҗәдә хас. Әнә, абыйсы Иван быел «СК - 5» комбайны белән хуҗалыкта гына түгел, тулаем район күләмендә дә иң күп ашлык суктыручы буларак танылды. Ә Николай - нәкъ менә аның ярдәмчесе иде.

Николай кышкы чорда да сынатмый. Дуңгыз фермасында эшли ул. Хезмәтен җаны - тәне белән бирелеп башкара. Шулай да күңеле күбрәк техникага тартылуын яшерми һәм киләсе елдан мөстәкыйль рәвештә комбайн алып эшләргә ниятли.



**Рәсемдә: Мичурин исемендәге КХА әгъзасы Н.Николаев.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

Яңалыклар

## «Авыл кешесенә дә бәйрәм кирәк»

диделәр дә таңлылар авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре көнен үз ассоциацияләрендә матур итеп билгеләп үтәргә булдылар. Шимбә көнне колхоз ашханәсе механизаторлар карамагына тапшырылган иде. Биредә әүвәл хуҗалыкта быелгы кыр эшләренә йомгак ясалды. Хуҗалыкның баш агрономы Ф.Сираҗев үз чыгышында таңлыларның кырчылыкта әйбәт нәтиҗәләргә ирешүен билгеләп үтте. Хуҗалыкта бөртекле культуралардан уртача 55,7 центнер уңыш алынды, ә Рәис Фәхретдинов җитәкчелегендәге I кооперативта ул 69 центнерга җитте. Чөгендер уңышы исә II нче - Васыйл Сөнгатуллин звеносында мулрак булды. Агроном үз чыгышында азык хәзерләүгә дә күзәтү ясады, зур хөрмәт белән хезмәт алдынгыларының исемнәрен атады. Аннан Биккол урта мәктәбе коллективы игенчеләрне хөрмәтләп концерт куйды. Бәйрәм мул сыйлы өстәл артында тәмамланды.

Хуҗалыкның терлекчелек тармагында эшләүчеләр дә шулай җыелып бәйрәм итteләр бу көнне.

## Хезмәткә күрә хөрмәт

Безнең «Н - Октябрь элеваторы» акционерлык җәмгыятендә эшләгән кешене хөрмәтли беләләр. Намуслы эшләгән кеше - һәр бәйрәмнең түрендә. Әле менә авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү промышленносте хезмәткәрләре көнендә тагын бер кат тойдык без моны. Тантананы алып барган җитәкчебез Н.Н.Миназов быелгы ашлык хәзерләү сезонына йомгак ясап, гомуми уңышка өлеш керткән кешеләрнең берсенең генә дә фамилиясен әйтмичә калдырмады. Мастерлар Иван Малков, Әхәт Сәгыйров, Зөфәр Хәйретдинов, Камил Әхмәдиев, Рәүф Галимов исемнәрен атаганда, зал гөр килеп кул чапты.

Хәзерләүләр чорында вакыт белән дә, ял белән дә исәпләшмичә эшләгән Павел Никифоров, Владимир Шикаев, Владимир Емуков, Елена Абрамова, Мария Сиплакова, Әхтәм Хәсәнгатин һәм Николай Савгильдин хезмәтләре дә югары бәяләнде.

Гомумән, җыелыш дустанә атмосферада үтте. Бу күтәренкелек ашханәдә сый - нигъмәт тулы өстәлләр артында да сүрелмәде: хезмәтләренә тиешле бәя бирелеп, хөрмәт күрсәтүдән һәркем канәгать калды.

**Г.Гафуров.**
**Норлат шәһәре.**

Яңалыклар

Яңалыклар

### Терлекчелек - көнүзәк тармак

# Бары - бергә, югы - уртак булса гына

Күзгә кереп килгәндә нефтебаза ярдәмче хуҗалыгында терлекчелек каралтыларын кышка әзерләү җәһәтеннән шактый эш башкарылганлыгы, шуны ахырына җиткергән тәкъдирдә биредә малларны кышлату уңышлы гына барырга мөмкин булуы турында язган идек. Тик менә соңгы вакытта бу хуҗалыкта сөт җитештерү һәм хәзерләүнең бик нык кимүе борчый. Хәзер биредә бер сыердан уртача көнлек савым 2,6 - 2,7 килограмм тирәсе генә. Бу - район буенча иң түбән күрсәткечләрдән. Ә инде дәүләткә озатыла торган продукциянең күләме бөтенләй ташка үлчим.

Эш нәрсәдә соң? Хуҗалыкта бу уңайдан күп кенә сәбәпләрне китерәләр, әмма берсен дә аклану максатыннан әйтмиләр. Хәер, анысына җирлек тә юк. Ник дигәндә, элеккеге җитәкчелек вакытында җибәрелгән хаталар күз алдында булса да, хәзер алардан зарланудан мәгънә шул кадәр генә. Инде яңа җитәкчелекнең дә кайбер уйлап җиткермәүләре үзен сиздерә. Нәтиҗәдә хуҗалыкта мөгезле эре терлекләрнең баш саны былтыргы дәрәҗәдән һаман да азрак булып кала бирә. Әгәр тармакка мөнәсәбәт үзгәрмәсә, ул аерманың алга таба тагын да артачагына шикләнмәскә мөмкин әле. Яшь бозауларның такы - токы рационга куелып, инде күбесе салкын тиярдәй шартларга җиткерелгән, бүген - иртәгә бозаулыйсы сыерлар да силоска калдырылган икән, сәламәт үрчем алуга да, аның ныклы саклануына да әллә ни өмет булмаячак.

Шулай да тармакка мөнәсәбәт дигәннән бар гаепне җитәкчелектә генә күрергә димәгән, чөгендер ташу да тәмамланмаган шартларда бер рәис кенә кырыкка ярылсынмени? Фермада эшләүчеләрнең дә үз вазифаларына карашы бик җитди түгел. Югыйсә бит җитәкчелек терлекчеләрнең хезмәт һәм көнкүреш шартлары турында да кайгыртмый диеп булмый: абзарлар нигездә ныгытылган, механизмнар да төзек, фермада ашханә дә эшләп тора. Дөрес, кайбер мөһим мәсьәләләрдә катлаулылыклар килеп чыккалап тора анысы. Аерым алганда, бозаулату бүлегенә килә торган торбаларда су туңып, андагы малларны су белән тәэмин итү кискенләшкән. Тик монда бу эш өчен җаваплы кешеләрнең җавапсызлыгы да чагыла бит. Югыйсә, савым сыерлар абзарында торбаларда су була торып та кайбер тагаракларда боз катуы абзарның бер баш ишекләре рәтләп ябылмаудан икән, кайбер тагаракларның бөтенләй коры торуы, бары тик терлекчеләрнең җавапсызлыгыннан гына бит инде. Савучылар арасында да эшкә мөнәсәбәт төрлечә булуы гомуми нәтиҗәдә чагылмый калмый әлбәттә. Әле кайчан гына хуҗалыкта савучылар проблемасының элеккеге кискенлеге бетүе турында сүз алып бара башлаганнар иде инде, әмма соңгы вакытта анысы юк - юкта тагын сизелгәли һәм бу фәкать кайбер терлекчеләрнең җавапсызлыгыннан гына. Үстерү группасындагы малларны караучыларның эшендә дә җитешсезлекләр бар. Дөрес, монда да хезмәтне оештыру җәһәтеннән җитәкчелек барысына да өлгереп бетә алмый әле, аерым алганда, салам кайтарту проблемага әверелгән. Әмма шушында көн дә эшкә килә торган кешеләргә дә көн үтсенгә генә йөрергә димәгән бит.

Хуҗалыкның бу тармагындагы хәлнең шулай кискенлегендә аерым бер кеше генә гаепле дип булмый, сәбәпләр күп булган төсле, гаепләләр дә күп. Шуңа күрә хәлне уңайга төзәтү дә уртак эш итеп каралса яхшы буласы. Бары - бергә, югы уртак дигәндәй, барыбер бергә - бергә көн күрәсе бит.

**Р.МУЛЛИН.**

## Яңалыклар

### Автовокзал халыксыз тормый

Мәктәп каникуллары һәм бәйрәмнәр тирәсендә Норлат автовокзалында халык аеруча күп була. Узган бәйрәмнәрдә генә дә өч көн эчендә шәһәрара маршрутлар буенча Норлаттан 541 кеше озатылды. Шәһәр яны автобуслары да халык белән шыплап тулып китте. 6 - 8 ноябрьдә бу маршрутларда 628 пассажир күчерелде.

### Прокуратура... яңа нигезле

Бу көннәрдә Карл Маркс проспектында яңа төзелеп килә торган янгын депосы янында прокуратура өчен яңа бинага нигез салынды. Объектны прокуратура заказы буенча РСУ сала. Бөтен көнкүреш уңайлыклары булачак ике катлы бу бинаны төзүчеләр киләсе елның көзендә файдалануга тапшыруны планлаштыралар.

### Егетләр китә хезмәткә

Агымдагы атнадан район хәрби комиссариатында «урак өсте» яшьләре җиткән һәм медицина комиссиясе тарафыннан хәрби хезмәткә яраклы дип табылган егетләрне хезмәткә ала башладылар. Берничә көн эчендә генә дә комиссариаттан 50 егет озатылды инде.

# БЕЗ – САЛЫМ САГЫНДАГЫЛАР

**Салым системасы гомер - гомергә иң четерекле өлкәләрдән булды һәм шулай булып кала бирә. Ул гына да түгел, салым төрләре чамасыз күбәю, салым ставкаларының гаять югары булуы өстенә, салым түләүче предприятиеләрнең һәм оешмаларның икътисадый - финанс хәле дә торган саен кискенләшә баруы салым системасын, дөресрәге салымнарның үзвакытында түләнүенә ирешүне катлаулаңдырды. Шуңа күрә дә Россия Президентының 1991 ел, 21 ноябрь Указы белән дәүләт салым службасы төзелү, шул исәптән Татарстанда һәм районыбызда да салым инспекциясе оештырылу табигый иде.**

Аннан бирле узган вакыт эчендә салым системасында хәл катлаулана гына төшсә дә, салымнар түләүне контрольдә тотучы, аларның дөреслеген тикшереп чарасын күреп торучы органның булуы салым җыемнары мәсьәләсендә хәлнең элеккегедән барыбер яхшырак булуында ачык сизелә. Шул исәптән безнең район салым инспекциясе дә үз алдында торган катлаулы бурычларны башкару юнәлешендә нәтиҗәле генә эш алып бара.

Мәгълүм булганча, безнең инспекциягә предприятие һәм оешмаларның өч төп - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы бюджетларына һәм җирле бюджетка салымнарны үзвакытында һәм тулы күләмдә түләвен контрольдә тоту бурычы тапшырылган. Инспекциядә эш предприятиеләрнең табышына салым салу, турыдан - туры булмаган салымнар, җирле салымнар һәм физик затлардан салымнар җыю белән шөгыльләнүче дүрт бүлеккә йөкләнгән. Ә барлык мәгълүмат шул бүлекләрнең эшен координацияләүче үзәк - статистика һәм анализ бүлеге аша уза. Безнең коллективның болардан тыш та вазифалары шактый. Аерым алганда, сәүдә нокталарындагы инде өч йөзгә җыела һәм арта бара торган контроль - касса аппаратларын, сәүдә маркаларын һәм бәяләрне, базарларны контрольдә тотабыз, финанска бәйле башка күп кенә мәсьәләләр дә безнең игътибардан читтә калмый, бюджеттан тыш фондларга җыемнар тупланышы да безнең хезмәткәрләр карамагында. Шуңа күрә илледән артык кешене берләштергән коллективыбыз алдында торган бурычларның күпъяклы һәм катлаулы булуын күзаллавы кыен түгел. Һәм коллективыбыз шушы киеренке эшне намус белән башкара. Һәр бүлекне бу өлкәдә тирән мәгълүматлы һәм бай тәҗрибәле белгечләр җитәкли. Бүлек башлыкларыннан Люция Җиһаншина белән Тамара Степановна Муракаева бирегә беренче көннән үк эшлиләр, инспекция начальнигы урынбасары Гөлфия Гаделша кызы Ибраһимова, бүлек башлыгы Рәисә Нуретдин кызы Фәтхетдинованың да бу өлкәдә тәҗрибәләре зур, баш испекторлар Зилә Насыйбуллина, Гөлшат Моратова һәм башка бик күпләр үз эшләренә зур җаваплылык белән карыйлар, күп хезмәткәрләребез безнең сферада бирелә торган югары чиннарга ия. Быел унбер айда район буенча салымнар һәм салым булмаган түләүләрнең гомуми күләмен узган елның шул чорындагыдан 32,8 миллиард сумга диярлек, ягъни 35 процентка арттыруга ирешелгән икән, монда безнең коллективның да өлеше бәхәссез. Шул җөмләдән унбер айда җирле бюджетка гына да 74 миллард сумнан артыграк акча керде. Ә бу инде беренче чиратта бюджеттагыларның хезмәт хакы дигән сүз. Бер үк вакытта шушы вакыт эчендә салым буенча бурычларның узган елның шул чорындагыдан 80 миллиардка кимүенә ирешү дә үзенә күрә бер казаныш булып тора.

Билгеле, бу нәтиҗәләр берсе дә үзеннән үзе генә килми. Безнең хезмәткәрләр тугыз айда гына да 111 предприятиедә салым турындагы законнарның үтәлешен тикшереп, 95 очракта законны төрлечә бозу очракларына тап булдылар. Шулар нәтиҗәсендә, шулай ук камераль тикшерүләр буенча гына да бюджетка өстәмә рәвештә 30 миллиард сумнан артыграк акча эзләп алынды яки пени һәм штраф салынды. Бюджеттан тыш фондларга эзләп алынган суммалар 13 миллард сумнан артып китә. Болар үзе генә дә безнең инспекция хезмәткәрләренең һич тә кеше җилкәсендә яшәүчеләр түгеллеген, ә чагыштырмача әллә ни югары булмаган хезмәт хакларын да үзләренең эш нәтиҗәләре белән бишләтә аклауларын раслый.

Хезмәт хакын аклау дигәннән, безнең инспекция коллективы башкара торган күпсанлы эшләр арасында физик затлардан салымнар кебек гаять четрекле һәм вак, әмма бик мәшәкатьле эш тә бар. Аның физик һәм юридик затларның керемнәр турындагы декларацияләрен кабул итеп тикшерү кебек төренә хәзер күчемсез милеккә салым кебеге дә өстәлде. Соңгысы безнең хезмәткәрләрнең аеруча күп вакытын алса да, әле бу юнәлештә җыела торган салымнар суммасыннан чыгып караганда бу эшебез беренче карашка мәгънәсез дә кебек. Әмма алга таба һәр кешенең дә салым законнарын тайпылышсыз үтәвенә ирешү максат ителгән шартларда халыкның бу мәсьәләдә тәртипкә күнегә башлавы кыйммәт. Шуңа күрә бу өлкәдәге барлык мәгълүматларны компьютерга салу да киләчәктә үзен аклаячак дип уйлыйбыз. Сүз уңаеннан, хезмәтебезне компьютерлаштыру юнәлешендә соңгы вакытта гына да шактый эш башкарылды һәм бу киләчәктә эшебезнең нәтиҗәлелелегендә ачык чагылачак дип ышанабыз. Дөрес, әлегә хезмәт шартларыбыз һич тә мактанырлык түгел - бер эшләүчегә туры килә торган гомуми мәйдан 2,5 квадрат метрдан артмый. Шуңа күрә дә район хакимияте безнең инспекциянең үз бинасын салуга республика бюджетыннан акча юллау юнәлешендә нәтиҗәле эшли. Төзелешнең урыны һәм генераль подрядчысы билгеле инде һәм киләчәктә безгә дә, клиентларыбызга да иркен шартларда эшләргә насыйп булыр дип ышанабыз.

Ә башкарасы эш шактый әле. Бүгенге көнгә предприятиеләр һәм оешмаларның җирле бюджетка бурычы 34 миллиард сумга якын. Аның өчтән бере диярлек "Татнефть" АҖ һәм аның райондагы подразделениеләре өлешенә туры килә, Норлат шикәр заводының бурычы 1,7, МСОныкы 1,5 миллиард сум чамасы, Машина төзү заводы, "Сельхозтехника", МТС базасы, элеваторның бурычлары миллиардтан артыграк, юл төзү идарәсе, ит һәм сөт - май комбинатлары, "Агрохимсервис" һәм "Надежда" дәүләт предприятиесе дә иң зур бурычлылар исемлегендә. Билгеле, без салым түләүчеләрнең үзләренең дә хәле җиңел түгеллеген яхшы аңлыйбыз. Әмма салым турындагы гамәлдәге законнарның үтәлергә тиешлеге дә бәхәссез. Хәзер югары дәрәҗәдә тикшерелә торган салым кодексы бу өлкәдә эшне шактый гадиләштерүне күздә тотса да, җитештерүчеләрнең һәм хезмәт күрсәтү сферасының тотрыклы эшләвенә ирешми торып салым җыемнарын туплау җиңеләер дип өметләнәсе юк. Ә моңа ирешү, илкүләм үзгәрешләр белән беррәттән, эшләүче һәркемнең үз хезмәт вазифасын намус белән башкаруын да, шул ук вакытта законнарны, шул исәптән салым турындагы законнарны да санга сугуын да күздә тота. Ник дисәң, кайсы гына өлкәне алсаң да, товар җитештерүчеләр, хезмәт күрсәтүчеләр, шул исәптән сәүдә хезмәте күрсәтүчеләрнең дә эше бер берсенә тыгыз бәйләнгән бит. Кыскасы, салым сагында бер салым инспекциясе генә түгел, ә һәркем торырга тиеш.

**Г.МИННЕГАЛИЕВ,**
**район салым инспекциясе начальнигы,**
**салым службасының II ранг киңәшчесе.**

# Бурычларның берсе

**Бездә һәр елны кирәкле һәм гадел законнар кабул ителә, алар төрле катлам кешеләрнең мәнфәгатенә кагылалар. 1991 елның ноябрендә РФның "Сәяси репрессия корбаннарын реабилитацияләү турында"гы Законы артында Сталин хакимлек иткән елларда трагик язмышка дучар булган тулы бер буын мәнфәгате тора. Әлеге законның бер маддәсе реабилитацияләнгән гражданнарның милкен кайтару, аның бәһасен билгеләп акчалата компенсация алу мөмкинлеген бирә. Районда бу мәсьәләләр ничек хәл ителә?**

Бу елларда район хакимияте каршындагы комиссия тарафыннан сәяси репрессияләнгәннәрнең хокукларын торгызу буенча репрессияләнүчеләрнең турыдан - туры варисларыннан 50дән артык гариза каралды. Элеккеге "халык дошманнары" документларын актарганда, тарихның гаҗәеп борылышларына таң каласың: ул чакта көчләрен кызганмыйча кырда эшләгәннәрне ирексезләп туган йортларыннан аерганнар, ә бүген фермерлык һәм эшмәкәрлек дәүләт ярдәме белән ныгытыла - кешеләр акылларын, хезмәт һәм матди байлыкларын эшкә җигәләр бит.

Тагы. Коры гайбәт нигезендә бернинди гаепсез эшчәннәр йөзәрләп тимер рәшәткә артына озатылалар, ә бүген теләсә кайсы киоскыдан сәяси анекдотлар җыентыгын сатып алырга мөмкин.

Степан Сергеевич Щербаковның аянычлы язмышы гыйбрәтле. Ул 1896 елда Урта Камышлы авылында туа, кулга алынганчы Заготзерно бүлегендә балта остасы булып эшли. 1937 елның 6 августында бернинди нигезсез НКВД органнары тарафыннан сәяси тотрыксыз дип кулга алына. ТАССР НКВДсының кырыс өчлеге карары буенча 11 сентябрьдә иң югары җәзага хөкем ителә. 4 көннән соң аны Бөгелмәдә атып үтерәләр. Кичәге ярымнадан крестьянны нидә гаеплиләр соң: чит ил державасы файдасына шпионаждамы яисә хөкүмәткә каршы фетнә оештырудамы? Ә бит өйдә Степан Сергеевичны хатыны һәм 4 баласы - кызы һәм өч улы көтәләр. Кечесе Петрга бары 2 яшь була.

Сүз уңаеннан, репрессияләнгәннәрнең күбесе - колхозчылар, эшчеләр. Бүген комиссиягә гаделлекне торгызуны үтенеп, сөрелүчеләр балалары Красноярскидан, Магнитогорскидан, Пермь, Чиләбе өлкәләреннән мөрәҗәгать итәләр. Менә Себердән 75 яшьлек Александра Григорьевна Портняшная хаты: Алар Мамыкта яшәгәннәр. Әти - әниләрен дүрт балалары белән раскулачивать итеп Красноярск краена сөргәннәр. Александра Григорьевна үзе - Бөек Ватан сугышы ветераны, I группа инвалид. Әлбәттә, аның гаризасы игътибар белән каралачак.

- Гаризадан тыш,- ди комиссия рәисе, район хакимияте юрисконсульты Ю.А.Муракаев,- реабилитация турында белешмә, конфискацияләнгән милек турында архив мәгълүматлары кирәк. Кайберәүләргә алдан судка мөрәҗәгать итәргә туры килә. Чираттагы утырышта карау өчен янә 6 эш әзерләнде.

Акчалата компенсация белән мәсьәлә авыррак тора. Район хакимиятенең финанс бүлеге мөдире урынбасары Г.Н.Сафина аңлатуынча, бу сумма Русиядәге 100 минималь хезмәт хакыннан артык булмаска тиеш (ягъни, 8 млн. 349 мең сум). Акча аларга саклык банкы яки элемтә бүлекчәләре аша күчерелә. Компенсация 1 ай эчендә түләнергә тиеш, райфинбүлек аны үзвакытында башкарырга тырыша. Билгеле, мөмкин булганда. Кызганычка каршы, финорган соңгысы белән бик иркенли алмый шул.

Тиешле түләүләр башкарылгач, финансистлар финанс Министрлыгы каршында отчет тоталар һәм бу түләнгән средстволар федераль бюджет аша каплана.

Әлеге проблемалар хәл ителер дип ышанабыз. Җәмгыять бит моннан тыш та үз гражданнары алдында зур бурычлы.

**Т.АЛЕКСЕЕВА.**

# Чирен яшермәгән... үлмәс

## "ЯШӘҮ" БЕЛӘН "ҮЛЕМ" АРАСЫНДА

Саннар буенча фикер йөртсәк, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү буенча "Надежда" дәүләт предприятиесендә быел бераз алга китеш бар. Узган елның шул чоры белән чагыштырганда быелның тугыз аенда халыкка 748 миллион сумлык хезмәт күрсәтелгән. Бу - аннан элеккеге елдагыдан 200 миллион сумга күбрәк. Авылга хезмәт күрсәтү күләме дә 22 миллион сумга үскән. Көнкүреш техникасын ремонтлау, фотография, чәчтараш хезмәте күрсәтү күләме дә күпкә арткан. Шушы чорда товар әйләнеше 622 миллион сум тәшкил иткән.

Белгеч булмау сәбәпле озак вакыт биктә торган аяк киемнәре ремонтлау цехы янәдән ачылган. Хезмәт күрсәтү бәяләре кимрәк куелгач, бирегә мөрәҗәгать итүчеләр дә аз түгел.

Башка үзгәрешләр дә бар. Яңа цех - ашыгыч фото 40 минут - 1 сәгать эчендә теләсә нинди төсле, үлчәмле фотоны ясый да бирә. Химик чистарту цехы да әйберләр кабул итә башлаган: югыйсә, соңгы вакытта ремонт таләп ителү һәм башка җитди сәбәпләр аркасында эшсез тора иде ул.

Сәүдә дә үсеш алган. Яңа ачылган "Бытовик" кибете аркылы предприятие үзе җитештергән юрган, кием - салым, махсус эш киемнәре һәм башкалар - барлыгы 622 миллион сумлык товар реализацияләгән. Файдасын бер белеп алгач, шунда ук барлык марка автомашиналар өчен запас частьләр бүлеге ачылган.

Гомумән, саннар предприятие файдасына сөйли. Әмма шулай булуга да карамастан, оешма ярым үле хәлдә бүген. Цехларның берничәсе ябык, гамәлдәгеләре тулы көчкә эшләми, җиһазлар искергән, чимал сатып алу өчен акча юк. "Акча" димәсәң хәтере калырдай хәләл хезмәт хакларын да берничә айлап ала алмыйлар бит кешеләр. Гомумән, проблемалар чиктән ашкан. Аның җитәкчесе Евгений Абрамов та яшерми боларны. Быелның тугыз аенда 258 миллион сумлык зыянга эшләү дә предприятиенең үз хисабына үзе яши алмаслыгы турында сөйли. Бәлки, бу служба бөтенләй кирәкмидер Шуңа җавап табу максатында шәһәрлеләрнең фикерләрен дә өйрәнергә булдык без.

- Базар булганда, көнкүреш хезмәте күрсәтүнең альтернатив службалары яшәгәндә РПУның кирәге юк,- диде НГДУда эшләүче Г.Степанова.

- Кирәк,- диде эштән кыскартылып хезмәткә урнаштыру бюросында учетта торучы Гөлия Г. һәм тезеп китте: иске бүрегемне кире сүтеп кызыма баш киеме тектердем, ательедан арзан бәягә халат алдым - анда теккән базардагылар белән чагыштырмалы түгел - нык...

"Бытовик" кибетенә эш киеме эзләп килгән Җәмилә дә шундый ук фикерне куәтләде. Күпчелек - икенче якта иде. Димәк, көнкүреш хезмәте кирәк безгә.

- Предприятиене тәмам "үтереп" бетерү аз тәэмин ителешле халык катламын авыр хәлдә калдырыр иде. Әмма хәзерге авыр шартларда да аны яшәтү өчен бүгеннән бөтенләй үзгә юл сайлау кирәк. Шәхсән үзем мин цехларны шәхси милеккә бирү ягында,- диде Евгений Владимирович һәм үз планнары белән бүлеште.

## БАШКА ЮЛ ЮК

Бүгенге көндә предприятие халыкка 11 төр хезмәт күрсәтә. Хезмәтләрнең берсе генә дә икенчел түгел. Суыткычлар, сәгатьләр төзәтү, чәчәкләр, гравировка ясау... Зур чыгымнар таләп ителсә дә, авылдагы комплекслы пунктларны да ябу мөмкин түгел: болай да инде шактый кимеп, 10ау гына калды алар. Предприятиедән атнаның 4 көнендә пунктка белгечләр килә: телевизор төзәтәсеме, башка төр көнкүреш техникасымы, барысы өчен дә шәһәр үзәгенә йөрү мөмкинлеге юк бит кешеләрнең. Оешма җитәкчелеге исә киләчәктә бу пунктларны кибетләр итәргә дә ниятли әле: көнкүреш хезмәте белән бергә халыкка сәүдә хезмәте дә күрсәтәчәкләр әле алар. Кибет дигәннән, предприятие быелдан үз кибетләрендә азык - төлек бүлеген дә ачуны планлаштыра.

Җитәкчелек кайчандыр кул селтәнгән тире эшкәртү цехын да торгызырга ниятли. Капиталь ремонттан соң яңа җиһазлар куеп, хәзерлекле кадрлар белән сыйфаты буенча элеккегедән күпкә үзгә тире эшләп чыгарырга планлаштырыла. Башка цехларда да акрын булса да эш бара. Боларның барысы да шәхси милеккә күчү юлындагы бер адым - хәзерләнү этабы дияр идек без. Әйтергә кирәк, ул уңышлы үтә. Октябрь аенда предприятиедәге башка чыккан чәчтараш цехы мисалында да ачык күренә ул (бу турыда тәфсилләп язарбыз әле без). Мөстәкыйль хуҗалык итүдән канәгать коллектив. Ә ни өчен әле тегү цехы, ритуаль хезмәт күрсәтүчеләргә дә мөстәкыйль яшәмәскә ди? Уңай үрнәк башка подразделениеләрне дә хәлиткеч адым ясарга этәрер, мөгаен. Яшәргә тиеш, халыкка кирәк хезмәтләр бит болар.

**Р.ГИНЯЕВА.**



"Заря" КХАсына урып - җыюны башкарып чыгулары җиңел булмады быел. Иске техника һәрвакыт ватыла, төзәтергә запчастьләр җитми, ә ягулыкка кытлык турында әйтеп тә торасы юк. Шуңа карамастан якушкинолылар җыелма отряд эшчәннәре ярдәме белән иң җаваплы кампанияне җиңеп чыга алдылар. Вячеслав Ермилов хуҗалык уңганнарының берсе. Ул быел "ЗАВ - 20"гә җаваплы булып, ашлыкның үзвакытында чистартылып торуын тәэмин итте. Фотохәбәрчебез Н.Азизов аны шундый кызу көннәрнең берсендә төшереп алган.

**Рәсемдә: "Заря" КХАсыннан В.Ермилов.**

## Янгыннар саны кимеде

1997 нче елның 9 аенда районда 52 янгын очрагы теркәлде, бу узган елның шул чорындагыдан 20 процентка кимрәк. 1997 нче елда янгыннарда үлүче кешеләр саны 1гә арткан, юк ителгән корылмалар саны кимегән. Турыдан - туры зыян да 14 процентка азрак. Шушы чорда шәһәрдә 18, авылда 34 янгын очрагы теркәлде.

Иң киң таралган сәбәпләр нинди соң? Тәмәке тартканда саксызлык күрсәтү, мичләрнең төзексезлеге һәм аларны файдалану кагыйдәләрен бозу, балаларның янгын белән шаяруы. Ә менә ут белән саксыз эш итү, төртеп яндырулар кебек очраклар кимегән. Элеккегечә үк янгыннарның байтак өлеше электротехник сәбәпләр буенча килеп чыга. Бу дәүләт янгын күзәтүе инспекторлары һәм тулаем Норлат - Октябрь янгын бүлегенең Энергонадзор һәм Агропромэнерго службаларының янгыннарны кисәтү буенча йомшак эшләүләре турында сөйли. Шәһәр, Чулпан һәм Егоркино җирле үзидарәләре Советлары территорияләрендә янгын чыгу проценты югары.

**Ә.ӘЮПОВ,**
**Норлат - Октябрь янгын бүлегенең дәүләт янгын күзәтүе инспекциясе өлкән инспекторы, эчке служба капитаны.**

*СПОРТ*

## Егетләрне көрәш мавыктыра

Физик хәзерлек буенча балалар - яшүсмерләр клубы балаларның спортның популяр төре - милли көрәш белән кызыксынуын көчәйтү максатында күп нәрсә эшли. Бүгенге көндә мәктәпләрдә клубның милли көрәш буенча филиаллары дистәдән артык булуы да шул хакта сөйли. Яшүсмерләрнең осталыгын арттыруга хезмәт итүче ярышлар да еш үткәрелә. Әле менә узган якшәмбедә дә клубта шау - гөр килеп ярышлар үтте. Анда Югары һәм Түбән Норлат, Чулпан, Фома, Богдашкино, Зирекле, хәтта Яңа Әмзә мәктәбеннән дә килгәннәр иде спортчылар. Ярышта катнашучылардан ике команда клуб секцияләрендә шөгыльләнүче шәһәр укучылары иде.

Ярыш 10 үлчәү категориясендә барды. 27 килограммга кадәрлеләр арасында Түбән Норлат егетләре аеруча нәтиҗәле көрәштеләр. Бикиниев беренче, Әбделмәнов өченче урыннарны яуладылар. Шәһәрнең икенче мәктәбеннән Мөлеков исә икенче булды.

Гомумән, Түбән Норлат мәктәбе укучыларының байтагы авылларына җиңүче булып кайттылар. Ишниязов, Дәүләтшәрипов, Рәхмәтуллин, Ашуров, Бикташев, Вәлиев, Ильмухин төрле үлчәү категорияләрендә призлы урыннарга чыктылар. Югары Норлаттан Әһлиуллин, Кәбиров һәм Мусин, Чулпаннан Варламов, Мингалимов, Давыдов, Варламов, Фәйзуллин, Ибраһимов, Нуретдинов та киеренке көрәшеп, яхшы нәтиҗә күрсәттеләр. Шәһәр мәктәпләре яшь спортчылары Әбделханов, Гыймранов (1 нче мәктәп), Гозәеров, Зәйнетдинов, Сәйфуллин һәм Зәйнетдинов (3 нче) та үзләренең көрәшне яратуларын тагын бер кат расладылар.

Якшәмбе көн киеклеле Гафиятуллин, Зирекле егетләре Галиуллин һәм Сәгыйров өчен дә сөенечле булды: үз үлчәү категорияләрендә җиңүче булдылар алар да. Богдашкинолы Шәрипов 60 килограммга кадәрле үлчәүдә лаеклы рәвештә өченче урын яулады.

Шунысы куанычлы, гомер - гомергә көрәш буенча ярышлардан читтә калучы Яңа Әмзә егетләре дә килделәр әлеге чарага. Гатин 50, Фәссахов 65 килограммга кадәрле үлчәүдә икесе дә икенче урынга чыктылар.

## "Исәнме, кадерле редакция!"

Әгәр безнең район журналистларына сез кайсы жанрны яратасыз дип сорау бирсәләр, алар һичшиксез "хатларны" диярләр иде. Сезнең, укучыларыбызның хатларын. Редакциягә аларның төрлеләре килә - кыскалары да, озыннары да, тулы бер коллектив имза куйганнары да, бер автор хатлары да, проза яки шигырь рәвешендәгеләре дә, усал тәнкыйть яки рәхмәт хатлары да. Тик аларның һәммәсе бер үк без өйрәнгән сәламлаудан башлана: "Исәнме, кадерле редакция!".

Елның икенче яртысында почта безгә 200гә якын хат китерде. Аларның кайсылары шунда ук җыюга җибәрелә, икенчеләре соңрак кулланыла. Көнкүреш - яшәеш проблемаларына кагылган үтенеч - хатларның бер өлешен без урыннарга тикшерү өчен җибәрәбез, аларның нәтиҗәләрен газетада бирәбез.

Соңгы яртыеллыкта да безнең иң актив авторларыбыз булып гадәттәгечә И.Сандлер, А.Костин, В.Комолов, М.Әюпов, Н.Хәмидуллин, В.Бурайкин, А.Дмитриев (Норлат), Ж.Шакиров (Кәкре Атау), З.Исмәгыйлова (Кычытканлы), С.Фәтхетдинова (Яңа Әмзә) калдылар. Александр Петрович Костин, мәсәлән, шахмат дөньясындагы бер генә яңалыкны да игътибардан читтә калдырмый. В.Комолов көндәлек мәшәкатьләр арасында да якты вакыйгалар һәм кызыклы штрихлар таба белә. Ә яшь коллегабыз Җәлил Шакиров акыллы, объектив итеп, җылылык белән үз хуҗалыклары эшләре һәм кешеләре турында сөйли белә. Сүз уңаеннан, әйләнә - тирәбездәге кешеләр - иҗат өчен саекмас чишмә ул. Үз коллегалары һәм якташлары турында безгә Н.Васильев, Т.Фадеева (Норлат), А.Андреева (Елаур), М.Свешникова (Заречный), Ф.Мөхәммәтова (Югары Норлат) җылы язмалар җибәрәләр. Күп авторлар иҗтимагый - сәяси, социаль характердагы вакыйгалар һәм истәлекле даталарны игътибардан калдырмыйлар. Мәсәлән, II Бөтендөнья татар конгрессыннан тәэсирләре белән К.Ямалетдинова уртаклашты. Ф.Михейкин Якушкино авылының 260 еллыгы, Ж.Камалов Кычытканлы авылы тарихы турында ныклы фактларга таянып төзелгән тарихи язмалары белән уртаклаштылар.

Без газетаның яңа авторлары пәйда булуга да чын күңелдән шатланабыз. Бәлки сез дә, хөрмәтле укучыларыбыз, үз каләмегезне сынап карарсыз? Без сезнең хатларны һәрчак көтеп калабыз.

**Хатлар бүлеге.**

# Безгә язалар Безгә язалар

## Сәламәтлек сагында

Норлатта сине һәрвакыт ачык йөз белән каршы ала, сәламәтлегең турында кайгыртучанлык күрсәтә торган урын бар. Бернинди арттырусыз аны Норлатның оҗмах почмагы дип атар идек. Ул - «Норлатнефтеразведка» санаторий - профилакторие.

Гаҗәпләнеп туймыйсың: халыкка җайлы булсын өчен профилакторий коллективы күпме тырышлык, күпме көч куйган. Уңай, кухняда искиткеч тәмле һәм туклыклы ризык әзерлиләр, һәркайда чисталык, пөхтәлек, дустанә атмосфера хөкем сөрә - болар һәммәсе бирегә килүчеләрнең ялын нәтиҗәле итә. Шул тәртипләрне тудыручы коллективны җитәкләүче баш табиб Р.Ю.Вәлиевага безнең рәхмәтебез зур.

Биредә йөрәк - кан тамырлары, ашказаны - эчәк, нерв авырулары һәм терәк-хәрәкәт органнарын дәвалау сеанслары үткәрәләр. Тиешле инъекцияләр, дарулар, витаминнар бирелә, электр белән дәвалау билгеләнә. Стоматология кабинеты эшли.

Ләм белән дәвалану өчен кешеләр ерак курортларга, санаторийларга барып йөриләр. Бу мәсьәләдә норлатлыларга профилакторийда юл ачык. Дәвалау өчен ләм Бәкердән китерелә. Персоналның игътибарлы карашы биредә дәваланучылар өчен икеләтә куаныч.

Халык медицинасыннан мәгълүм булган ылыс, скипидар, диңгез тозы белән дәвалау ванналары нервлар киеренкелегеннән коткаралар, буыннар сызлавыннан, йокысызлыктан аралыйлар. Ә циркуляр душ рухи күтәренкелек бирә, кан әйләнешен яхшырта. Озакламый биредә тренажер залы, фитобар ачу планлаштырыла.

Профилакторийда сәламәтлекне ныгытып кына калмыйсың, ә чын мәгънәсендә ял итәсең, стресстан, нервлар тынычсызлыгыннан, ару - талудан арынасың. Процедураларның һәммәсе дә рухи һәм физик яктан яшәртә, яңа көч һәм үз - үзеңә ышанганлык тудыра. Болар барысы да профилакторий коллективының фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә барлыкка килә.

Чын күңелебездән сезнең гаиләләрегезгә бәхет, иминлек телибез.

**Ял итүчеләр Гыйләҗев, Мортазина, Ибраһимова, Борһанов һәм башкалар.**

## Тәмле дә, файдалы да

Әчегән сөт продукты буларак, кефир Россиядә күптәннән мәгълүм. Ул каймакка охшаган, составында спирт, углекислый газ бар. Кефир әчегән сөт һәм спирт продуктларының катнаш әчүеннән барлыкка килә. Әчегән сөт стрептоккок һәм таякчыклар, ә спирт чүпрә ярдәмендә әчелә.

Кефирны аертылган яки аертылмаган сөткә кефир гөмбәчекләре яки әче сөт бактерияләренең чиста культураларыннан һәм чүпрәдән ясалган оеткы кушып әзерлиләр.

Аксым һәм майның микъдары буенча кефир гади сөттән бик азга гына аерыла, бары тик сөт составындагы шикәр әчетү вакытында сөт кислотасына әйләнә, ул уртача 0,7дән 1,1 процент тәшкил итә. Сөт кислотасы тәэсирендә казеин, ягъни сөт аксымы вак кисәкләргә әйләнә, нәтиҗәдә кефирның сөт белән чагыштырганда үзләштерелүчәнлеге арта: бер сәгатькә кефирның 92 проценты, ә аертылмаган сөтнең 32 проценты гына үзләштерелә.

Кефирның үзләштерелүчәнлеге оешкан аксымның углекислый газ тәэсирендә көпшәкләнүеннән дә килә, шуңа да ул ашкайнату ферментларының тәэсиренә тиз бирешә. Әчегән сөт продуктлары ашкайнату трактыбизләре эшчәнлегенә нык йогынты ясаганга, интенсив рәвештә ризыкның тиз үзләштерелүенә китерә торган ферментлар бүленеп чыга.

Бу продукт сафландырып җибәрә, аппетитны күтәрә, эчәклекнең эшчәнлеген арттыра.

Составында спирт һәм углекислый газ булган кефир сулыш органнарына, кан тамырларына, хәрәкәт итү үзәгенә һәм үзәк нерв системасына уңай йогынты ясый, нәтиҗәдә организмның окисьлашу - яңадан терелү процессы яхшыра.

Кефирны даими рәвештә куллану организмны А,Д,Е кебек әче сөт микроорганизмнары белән синтезлана торган витаминнарга баета. Шулай ук ул сөякләр һәм кеше организмының башка тукымалары составына керә торган кальций тозлары, фосфор, магнийга, җиңел үзләштерелә торган алыштыргысыз аминокислоталарга бай.

**Н.КУДРЯШОВА,**
**сөт-май комбинатының ОТК начальнигы.**

# 02 хәбәр итә 02 хәбәр итә 02 хәбәр итә

02 хәбәр итә 02 хәбәр итә 02 хәбәр итә

## 21 нче километрдагы һәлакәт

Бозлавык, кар яки яңгырда безнең юллар аеруча куркыныч. 10 нчы ноябрьдә Норлат - Әлмәт юлының 21 нче километрында ГАЗ - 3102 шоферы 22 яшьлек И. руль белән идарә итә алмыйча каршы полосага чыга һәм М - 412 автомашинасына бәрелә. Сак булыгыз! Истә тотыгыз: көн саен Рәсәй юлларында 100дән артык кеше һәлак була.

## Электгегечә үк кыйммәт

Авторезина һәм автомобильләр өчен запас частьләргә бәя һәрвакыт югары. «Комбайн» һәм Мичурин исемендәге КХАлардан урлаулар да шул турыда сөйли. Соңгысында аның нәтиҗәләре аеруча сизелерлек. 32 КамАЗ, 6 «Урал», 6 «Газель» һәм 1 УАЗ резинасы. Караңгы ноябрь көннәренең берсендә әлеге хуҗалык дуңгыз фермасыннан тагын ике баш дуңгыз да урланыла.

## Аракы кабергә керткән

Түбән Чаллы авылында яшәүче Н.ны спиртлы эчемлекләрне күп эчү кабергә керткән. Чама белен эчкәндә генә аның шатлык китерүен онытып ул яхшы иттереп күңел ачкан һәм ноябрь бәйрәмнәре тирәсендә җан биргән. Гади генә итеп әйткәндә организмы түзмәгән...

## Салкыннар һәм явызлык корбаны

Кешегә ялгызы гына яшәве бик авыр. Төрнәс авылында яшәүче Х.да кайчандыр яхшы мич чыгаручы булган. Гаиләсе таркалган, янгын нәтиҗәсендә өйсез калган, кайчак үзенең салкын сараенда да кунгалаган. 7 нче ноябрь кичендә шунда ук үлгән дә. Кешегә ялгыз яшәве бик авыр...

## Иртән, 4 сәгатьтә

Гаиләдә аңлашуның сирәге генә эре гауга, сугыш яисә кулга пычак тоту белән тәмамланмый. Соңгы очракта норлатлы А. корбан ролендә булды. Аңа хатыны үз куллары белән пычак кадады. Бу иртәнге сәгать 4тә булды.

## Күңелсез хроника

Бер атна дәвамында, 3 нче ноябрьдән 10на кадәр эчке эшләр бүлеге дежур частена вак хулиганлык эшләгән өчен 25 кеше, исерек килеш 11 кеше китерелде. Җәмәгать тәртибен бозучылар исемлегенә Ключи поселогыннан пенсионер С. һәм Казан ветеринария академиясеннән А.да керә.

## Исерткеч салам

«Көнчыгыш» еланы Норлатка да килеп җитте. 6 нчы ноябрьдә шәһәр үзәгендәге йортларның берсендә район эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан мәк саламы алына. 3,6 килограммга тарта ул.

# КОТЛЫЙБЫЗ!

*Кычытканлы авылында гомер итүче сөекле* ***әниебез Зәйнәп, әтиебез Әфкать Исхаковларның*** *матур, тату гаилә коруларына 20 ноябрьдә 40 ел тула.*

*Әти, әни, яшәгез сез*
*Авырлыкларны белмичә.*
*Тормыш юлларыгыз үтсен*
*Кайгы - хәсрәт күрмичә.*

***Барлык оныкларыгыз исеменнән кызыгыз Зөлфия.***

Норлат шәһәрендә яшәүче кадерле әтиебез **Минзаһит Зәйдулла улы Манәповка** 21 ноябрьдә 50 яшь тула. Йөрәктәге иң изге хисләр, җир йөзендәге иң матур теләкләр аша чын күңелдән туган көнең белән котлыйбыз һәм сәламәтлек, бәхетле картлык, озын гомер телибез.

Котлы булсын, әткәй, туган көнең,
Матур булып атсын таңнарың.
Рәхәт яшә калган гомереңне,
Игелеген күр һәрбер балаңның.

**Иң изге теләкләр белән әниебез Гөлсәрия, улларың Миннәсих, Рәмис, Әнфир, киленең Лилия һәм оныгың Алина.**


# Белдерүләр

### САТАБЫЗ

**Кормышта өч бүлмәле фатир.** Тел.: 5 - 23 - 49.

***

**4 х 5,5 метрлы чанадагы гараж, кыйммәт түгел.** Адрес: Нефтьчеләр ур., 14 - 25.

***

**1992 нче елгы, әйбәт хәлдәге «Москвич - 2141».** Адрес: 60 лет Октября ур., 7 - 7, тел.: 5 - 13 - 74, 17 сәг.тән соң.

***

**Ягу һәм су җылыту өчен АОГВ казаны, тарту торбасы. Бәяләре кибетнекеннән арзан.** Тел.: 2 - 29 - 71.

***

**Туй күлмәге.** Тел.: 5 - 26 - 19.

***

**Алып китү өчен 6 х 4 метрлы чанадагы гараж, кыйммәт түгел.** Тел.: 2 - 28 - 52.

***

**ВАЗ - 2101, кыйммәт түгел.** Тел.: 2 - 28 - 02.

***

**Ашыгыч рәвештә сүтү өчен йорт, йорт яны корылмалары да бар.** Тел.: 5 - 28 - 08.

***

**Кулланышта булган стенка һәм кухня гарнитуры.** Тел.: 2 - 29 - 47.

***

**Барлык уңайлыклары булган 4 бүлмәле фатир.** Тел.: 2 - 14 - 46.

***

**20 сутый җире белән йорт, кыйммәт түгел. Чулпан авылында Усмановларга мөрәҗәгать итәргә.** Тел.: 3 - 82 - 83.

***

**Әфган поселогында фундаменты белән участок, авариядән соң ВАЗ - 21053 кузовы, кыйммәт түгел.** Тел.: 5 - 26 - 08, 16.30 сәг.тән соң.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**«Татнефтетранс» ПКПСы ликвидацияләнә. Дәгъвалар белдерү басылган көннән бер ай эчендә кабул ителә.** Тел.: 65 - 9 - 59.

***

**Сөләйманов Рамил Минсәгыйрь улы исеменә документлар табучының бүләк бәрабәренә Завод тыкрыгы, 9 - 32 адресы буенча иясенә тапшыруын сорыйбыз.**

**«Надежда» дәүләт предприятиесе тегү машиналары ремонтлый.** Адрес: К.Маркс ур., «Модалар ательесы».


Кычытканлы урта мәктәбе коллективы абыйсы үлү сәбәпле **Константинов Андрей Геннадий** улының тирән кайгысын уртаклаша.


БАШ МӨХӘРРИР Р.Ф.ЖАМАЛИЕВ.
МӨХӘРРИР О.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә. Заказ N 9698.